**ГЛАВА**
**Бимского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

ул. Ленина, д. 2а, с. Бима, Агрызский район, 422219

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Бима авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Ленин ур., 2а, Бима авылы, Әгерҗе районы, 422219

Тел/факс: (85551) 3-37-18. E-mail: Bim.Agr@tatar.ru, www.agryz.tatarstan.ru


01.11.2023 Бима авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Пеләмеш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Пеләмеш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 11 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Пеләмеш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Пеләмеш авылының Яшьләр, Заречная урамнары өчен вак таш сатып алу һәм җәю).

2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, автозапчастьләр сатып алу).

3. Урамнарны яктырту өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу һәм урнаштыру.

4. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, ташу һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау(материаллар сатып алу).

5. Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау, аларга якын территорияләрне төзекләндерү (тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү; үләннәрне һәм чүп үләннәрне чаптыру; трактор өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу; кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы авария һәм коры яшеллек утыртмаларын кисү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Пеләмеш авылы, Ленин урамы, Пеләмеш авыл клубы.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Э.И. Михайлов

